ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**19.11.2019**

Зеленодольск
шәһәре

**КАРАР**
**№ 2488**

Зеленодольск муниципаль районы Олы Карагуҗа авыл җирлеге муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш корылмалары буенча комиссия төзү турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 8, 31 нче статьялары һәм «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 нче елның 6 нчы октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14 нче статьясы нигезендә Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. 1 нче кушымта нигезендә Зеленодольск муниципаль районы Олы Карагуҗа авыл җирлеге муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш корылмалары кагыйдәләре буенча комиссия төзергә.
2. Зеленодольск муниципаль районы Олы Карагуҗа авыл җирлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш корылмалары кагыйдәләре буенча комиссия турында нигезләмәне 2 нче кушымта нигезендә расларга.
3. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләр составындагы Зеленодольск муниципаль районы рәсми порталында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) урнаштырырга.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплыгымда калдырам.

Җитәкченең беренче урынбасары А.В. Старостин

Зеленодольск муниципаль районы
Башкарма комитетының
2019 нчы елның 19 нчы ноябрендәге
2488 нче номерлы карарына карата
1нче кушымта

Зеленодольск муниципаль районы Олы Карагуҗа авыл җирлеге муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш корылмалары кагыйдәләре буенча комиссия составы

| | | |
|---|---|---|
| 1. | Минһаҗев Марат Ринат улы | Олы Карагуҗа авыл җирлеге башлыгы |
| 2. | Якупова Энҗе Рөстәм кызы | Башкарма комитеты Олы Карагуҗа авыл җирлегенең әйдәп баручы белгече |
| 3. | Хөснетдинова Рузия Рафаэль кызы | Олы Карагуҗа авыл Советы җирлегенең 9 нчы номерлы сайлау округ депутаты |
| 4. | Хөснетдинова Әлфинур Маннап кызы | Олы Карагуҗа авыл Советы җирлегенең 8 нче номерлы сайлау округы депутаты |
| 5. | Камалиев Илшат Сөләйман улы | Олы Карагуҗа авыл Советы җирлегенең 1 нче номерлы сайлау округы депутаты |

Зеленодольск муниципаль районы
Башкарма комитетының
2019 нчы елның 19 нчы ноябрендәге
2488 нче номерлы карарына карата
2 нче кушымта

Татарстан Республикасы
Зеленодольск муниципаль районы
Олы Карагуҗа авыл җирлеге муниципаль берәмлегенең
җирдән файдалану һәм төзелеш корылмалары кагыйдәләре буенча комиссия
турында нигезләмә

## 1. ГОМУМИ НИГЕЗЛӘМӘЛӘР

Зеленодольск муниципаль районы Олы Карагуҗа авыл җирлеге муниципаль берәмлеге территориясендә җирдән файдалануны һәм төзелеш корылмаларын алып баруны җайга салу системасының нәтиҗәле эшләвен булдыру, эзлекле камилләштерү һәм тәэмин итү өчен Зеленодольск муниципаль районы Олы Карагуҗа авыл җирлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш корылмалары кагыйдәләре буенча комиссия (алга таба - Комиссия) төзелә.

Комиссия Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе карары нигезендә төзелә.

Комиссия даими эшли торган һәм үз эшчәнлеген билгеләнгән тәртиптә кабул ителгән, җирдән файдалану һәм төзелеш корылмалары кагыйдәләре нигезендә гамәлгә ашыра.

Комиссия үз эшчәнлегендә Россия Федерациясе законнарына, Зеленодольск муниципаль районы Олы Карагуҗа авыл җирлеге муниципаль берәмлеге җирле үзидарә органнарының норматив хокукый актларына, шулай ук әлеге Нигезләмәгә таяна.

Комиссия үз эшчәнлеген дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары, муниципаль предприятиеләр, учреждениеләр, шулай ук кызыксынган юридик һәм физик затлар белән үзара бәйләнештә алып бара.

## 2. КОМИССИЯ СОСТАВЫ

2.1. Комиссия составы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе карары белән раслана.

2.2. Комиссия рәисе булмаган очракта, аның вазыйфаларын комиссия рәисе урынбасары башкара.

## 3. КОМИССИЯ КОМПЕТЕНЦИЯСЕ

3.1. Комиссия компетенциясенә:

3.1.1. Җирдән файдалануны һәм төзелеш корылмаларын алып баруны җайга салу системасын эзлекле рәвештә Формалаштыру һәм камилләштерү процессын оештыру, шул исәптән җирдән файдалану һәм төзелеш корылмалары кагыйдәләрен эшләү, ә алга таба аларны тормышка ашыру;

3.1.2. Зеленодольск муниципаль районы Олы Карагуҗа авыл җирлеге муниципаль берәмлегенең җир биләмәләреннән файдалану һәм төзелеш корылмалары кагыйдәләрен эшләүгә бәйле рәвештә гражданнар һәм юридик затларның тәкъдимнәрен карау;

3.1.3. Ачык тыңлауларны оештыру һәм үткәрү:

- Зеленодольск муниципаль районы Олы Карагуҗа авыл җирлеге муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш корылмалары кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында;

- Зеленодольск муниципаль районы Олы Карагуҗа авыл җирлеге муниципаль берәмлеге территориясендә җир кишәрлеген яки капиталь төзелеш объектын шартлы рәвештә рөхсәт ителгән куллану төренә рөхсәт бирү турындагы сораулар буенча;

- Зеленодольск муниципаль районы Олы Карагуҗа авыл җирлеге территориясендә рөхсәт ителгән төзелешнең чик параметрларыннан капиталь төзелеш объектларын реконструкцияләүне кире кагуга рөхсәт бирү сораулары буенча;

- Зеленодольск муниципаль районы Олы Карагуҗа авыл җирлеге муниципаль берәмлеге территориясен планлаштыру проектлары буенча;

- Зеленодольск муниципаль районы Олы Карагуҗа авыл җирлеге муниципаль берәмлеге территориясен ызанлау проектлары буенча.

3.1.4. Ачык тыңлаулар нәтиҗәләре буенча бәяләмә чыгару, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы нигезендә тәкъдимнәр әзерләү кирә.

## 4. КОМИССИЯ ЭШЧӘНЛЕГЕ ТӘРТИБЕ

4.1. Комиссия кирәк булган саен, ләкин кимендә айга бер тапкыр җыела

4.2. Комиссия утырышы комиссия әгъзаларының билгеләнгән саныннан кимендә өчтән икесе катнашса, хокуклы дип санала.

4.3. Комиссия карары Комиссия әгъзаларының күпчелек тавышы белән кабул ителә. Тавышлар тигез булганда, рәис тавышы хәлиткеч булып тора.

4.4. Комиссия эшчәнлеген техник яктан тәэмин итү Зеленодольск муниципаль районының Олы Карагуҗа авыл җирлеге башлыгына йөкләнә.

.